ЦЕНТРАЛИЗОВАННАЯ РЕЛИГИОЗНАЯ ОРГАНИЗАЦИЯ
Духовное управление мусульман
Российской Федерации

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ

# ГЫЙД ӘЛ-ӘДХА – КОРБАН БӘЙРӘМЕ УҢАЕННАН

## РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ РӘИСЕ

## БАШ МӨФТИ ШӘЕХ РАВИЛ ГАЙНЕТДИН

# МӨРӘҖӘГАТЕ

**Мәскәү**
10 Зө-л-хиҗҗә, 1447 һиҗри ел
27 май, 2026 ел

بِسۡمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحۡمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

***Рәхимле, шәфкатьле Аллаһ исеме белән!***

**الحمد لله رب العالمين**

**والصلاة والسلام على رسولنا محمد**

**وعلى آله وصحبه أجمعين**

**أما بعد**

Җирдәге вә күк йөзендәге бар мәхлүкат тарафыннан макталучы, һәрнәрсәне Үз мәрхәмәте белән колачлаган галәмнәрнең Хуҗасы Аллаһу Сөбханәһу вә Тәгаләгә мактау булсын! Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлламгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм Кыямәт көненә кадәр алар юлында булучыларга Раббыбызның рәхмәте ирешсен!

السلام عليكم ورحمة الله وبركاته

**Аллаһы Тәгаләдән иминлек, Аның рәхмәте һәм бәрәкәте булсын!**

**Кадерле дин кардәшләрем!**

Россия Федерациясе мөселманнары диния нәзарәте исеменнән һәм шәхсән үзем барыгызны да бөек бәйрәм — Гыйд әл-Әдха белән ихлас йөрәктән котлыйм! Бу көнне дөньядагы ике миллиардка якын кеше Раббысына ихлас догалары аша мөрәҗәгать итә. Аларның йөрәге Аллаһы Тәгаләгә һәм Ул бар кылган мәхлүкатка мәхәббәт, корбан чалу һәм игелекле гамәлләр аша Аның чиксез рәхмәтенә ирешү өмете белән тулы.

Корбан бәйрәме төрле милләт, төрле тән төсендәге мөселманнарны берләштерә, Ислам йолаларына сакчыл караш тәрбияли. Бәйрәмнең нигезенә тирән әхлакый мәгънә салынган, ул рухи ныклык, басынкылык, шәфкатьлелек, якыннарыбызны ярату кебек һәр мөселманның күңеленә якын булган мәңгелек кыйммәтләрне искә төшерергә этәрә. Зө-л-хиҗҗә аеның бу көннәрендә хаҗилар Аллаһ каршындагы бурычларын үти һәм Аллаһ йортына омтылып, хаҗ кыла:

**وَلِلّهِ عَلَى النَّاسِ حِجُّ الْبَيْتِ مَنِ اسْتَطَاعَ إِلَيْهِ سَبِيلاً**

**«Һәм кешеләрнең Аллаһ каршында вазифасы Бәйткә (Кәгъбәгә) хаҗ кылудыр, әгәр алар моны үтәр хәлдә булсалар».**
(*«Әлү Гыймран» сүрәсе, 97 нче аять*).

فَصَلِّ لِرَبِّكَ وَانْحَرْ

**«Раббың өчен намаз укы һәм корбан чал»**
(*«Әл-Кәүсәр» сүрәсе, 2 нче аять*), — дип, Аны искә алалар һәм мактау сүзләрен ирештерәләр. Үзен

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм өммәтеннән санаган һәркем, дин кардәшләре янында булганда, зур шатлык хисләрен кичерә:

قُلْ بِفَضْلِ اللَّهِ وَبِرَحْمَتِهِ فَبِذَٰلِكَ فَلْيَفْرَحُوا هُوَ خَيْرٌ مِمَّا يَجْمَعُونَ

**«Әйт: «Бу - Аллаһының фазылы белән һәм Аның гына рәхмәте», шуңа шатлансыннар. Ул алар җыйганнан яхшырак»**
(*«Йунус сүрәсе», 58 нче аять*).

Корбан бәйрәмен билгеләп үтүнең тамырлары Ибраһим галәйһиссәлам һәм аның улы Исмәгыйль галәйһиссәлам белән бәйле тарихка барып тоташа. Ибраһим пәйгамбәргә, сынау буларак, төшендә яраткан улын корбанга китерергә боерык бирелә. Улын яратуына карамастан, ул Аллаһы Тәгаләнең әмеренә буйсына, ә улы әтисенә тел әктәшлек күрсәтә. Шулай итеп Ибраһим галәйһиссәлам белән Исмәгыйль галәйһиссәлам Аллаһны чиксез яратуын күрсәтә:

يَا أَبَتِ افْعَلْ مَا تُؤْمَرُ سَتَجِدُنِي إِنْ شَاءَ اللَّهُ مِنَ الصَّابِرِينَ

**«Әтием минем! Сиңа ничек боерылды — шулай эш ит һәм әгәр Аллаһ ихтыярында булса, син мине сабыр итүчеләрдән табарсың»**
(*«Саффат» сүрәсе, 102 нче аять*).

Ибраһим пәйгамбәр улын корбан итәргә ниятләп, яткыргач, ул шушы сүзләрне ишеткән:

يَا إِبْرَاهِيمُ قَدْ صَدَّقْتَ الرُّؤْيَا إِنَّا كَذَٰلِكَ نَجْزِي الْمُحْسِنِينَ

**«И Ибраһим! Син төшеңне раска чыгардың. Игелек кылучыларга Без шулай әҗерен бирәбез»**
(*«Әс-Саффат» сүрәсе, 104–105 нче аятьләр*).

Аллаһы Тәгалә улы урынына хайванны чалырга боерып, Ибраһим галәйһиссәламне туктаткан. Бу — ата кеше белән аның улына карата олуг мәрхәмәт күрсәтү. Әлеге тарих безне мөэмин-мөселманның авырлыкларга һәм сынауларга әзер булырга тиешлегенә өйрәтә. Авыр вакытта Аллаһ күндәмлек һәм сабырлык күрсәтүчеләргә һәрвакыт мәрхәмәтле.

Бүген, догаларыбыз Аллаһы Тәгаләгә ирешкән һәм гөнаһларыбыз кичерелгән вакытта, Галәмнәрнең Раббысына мөрәҗәгать итәм: йә Аллаһ, безне хаклык һәм тәкъвалык юлыннан алып бар, йөрәкләребездәге иманны ныгыт, күп изге гамәлләр кылырга бәрәкәтле муллык бир. Йә Рабби, безнең арадагы дуслыкны һәм кардәшлекне ныгыт. Россия халыклары арасындагы үзара аңлашу һәм ихтирамны һәм безгә кадәр яшәгән буыннарның нәсыйхәтен саклар өчен безгә көч һәм сабырлык бир. Табигать һәлакәтеннән соң Дагыстан халкына ярдәмен күрсәткән кардәшләребезнең изге эшен кабул ит! Ватаныбыз тынычлыкта, иминлектә яшәп чәчәк атсын.

وَعَدَ اللَّهُ الَّذِينَ آمَنُوا مِنْكُمْ
وَعَمِلُوا الصَّالِحَاتِ لَيَسْتَخْلِفَنَّهُمْ
فِي الْأَرْضِ كَمَا اسْتَخْلَفَ الَّذِينَ مِنْ قَبْلِهِمْ
وَلَيُمَكِّنَنَّ لَهُمْ دِينَهُمُ الَّذِي ارْتَضَىٰ لَهُمْ وَلَيُبَدِّلَنَّهُمْ مِنْ
بَعْدِ خَوْفِهِمْ أَمْنًا

**«Аллаһ сезнең арадан иман итеп, игелек кылганнарга,
алардан әүвәлге кешеләрне хәлифә кылганы кебек, аларны да җирдә хәлифә
итәчәген, янә алар өчен ошатып сайлаган диннәрен куәтләячәген
һәм куркудан соң аларга иминлек бирәчәген вәгъдә итте»**
(*«Ән-Нур» сүрәсе, 55 нче аять*).

Бу мөбарәк бөек бәйрәмдә без Аллаһы Тәгаләдән корбан малларыбызны кабул итүен һәм моның өчен бетмәс-төкәнмәс әҗерен бирүен сорыйбыз. Галәмнәрнең Раббысы кардәшләребезнең хаҗын, һәммәбезнең догасын һәм игелекле гамәлләребезне кабул итсен! Ихлас гамәлләр күңелләребездәге тәкъвалыкны һәм иманны ныгытсын!

Аллаһы Тәгаләдән фетнәләрне һәм низагларны туктатуын, Якын Көнчыгышта һәм бар дөньяда тынычлык һәм иминлек урнаштыруын, адәм балаларының йөрәкләрен үзара мәхәббәт хисләре белән тулыландыруын, Ватаныбызга тынычлык һәм тотрыклылык, гаиләләребезгә иминлек һәм сәламәтлек, авыруларга дәвасын һәм шифасын, ярлыларга һәм мохтаҗларга ризык һәм муллык бүләк итүен сорыйбыз!

Гыйд әл-Әдха мөбарәк, кадерле дин кардәшләрем!

Корбан бәйрәме мөбарәк булсын!

*Аллаһы Тәгаләдән иминлек сезгә, Аның рәхмәте һәм бәрәкәте булсын!*

والسلام عليكم ورحمة الله وبركاته

***Баш мөфти шәех Равил Гайнетдин,***
***Россия Федерациясе мөселманнары диния нәзарәте рәисе***